**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# Татарстан Республикасының дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары булмаган вазыйфалар биләүче Татарстан Республикасы Президенты Аппараты хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары турында

Татарстан Республикасының дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары булмаган вазыйфалар биләүче Татарстан Республикасы Президенты Аппараты хезмәткәрләренә социаль гарантияләр тәэмин итү һәм алар хезмәте өчен түләүне тәртипкә салу максатларында **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасының дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары булмаган вазыйфалар биләүче Татарстан Республикасы Президенты Аппараты хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләме Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының территориаль органы җитәкчесе секретаренең 11 163 сум тәшкил иткән вазыйфаи окладына тапкырлап исәпләнелә, дип билгеләргә.

2. Кушымтада бирелүче Татарстан Республикасының дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары булмаган вазыйфалар биләүче Татарстан Республикасы Президенты Аппараты хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмен санаганда кулланыла торган тапкырлау коэффициентларын расларга.

3. Татарстан Республикасының дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары булмаган вазыйфалар биләүче Татарстан Республикасы Президенты Аппараты хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләме, шулай ук айлык һәм башка өстәмә түләүләр күләме арттыру ягына бөтен бер сумга кадәр түгәрәкләнергә тиеш, дип билгеләргә.

4. Татарстан Республикасы Президенты Эшләр идарәсенә 2018 елның 1 апреленнән Татарстан Республикасының дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары булмаган вазыйфалар биләүче Татарстан Республикасы Президенты Аппараты хезмәткәрләренә хезмәт хакын Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары булмаган вазыйфалар биләүче Татарстан Республикасы Президенты Аппараты хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары турында» 2018 елның 22 мартындагы ПУ-240 номерлы Указы нигезендә түләүне тәэмин итәргә.

5. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары булмаган вазыйфалар биләүче Татарстан Республикасы Президенты Аппараты хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары турында» 2006 елның 16 июнендәге ПУ-223 номерлы Указы үз көчен югалткан дип танырга.

6. Әлеге Указ рәсми басылып чыккан көннән 10 көн узгач үз көченә керә һәм 2018 елның 1 апреленнән барлыкка килгән хокукый мөнәсәбәтләргә кагыла.

**Татарстан Республикасы**
**Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2018 ел, 22 март
№ ПУ-243